КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 21 май г.Казань № 427

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан РеспубликасыМинистрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 ноябрь, 866 нчы; 2014 ел, 8 май, 304 нче; 2014 ел, 17 май, 330 нчы; 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче; 2016 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 733 нче; 2018 ел, 20 март, 159 нчы; 2019 ел, 8 апрель, 274 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 нче пунктта «поселокларга» сүзләрен «шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә» сүзләренә алыштырырга;

2.1 нче пунктның икенче абзацында «2007» саннарын «2004» саннарына алыштырырга;

5.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Башка бюджетара трансфертлар алга таба аларны Татарстан Республикасының муниципаль районнары бюджетларыннан Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре бюджетларына – грант алучыларга бирү өчен Татарстан Республикасының муниципаль районнары бюджетларына (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　А.В.Песошин